| | | |
|---|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

24.09.2013 539-п

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.03.2013 ел, № 166 «А.Э. Калайда турында»гы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, йөкләнгән вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгында булган кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Административ регламент раслау турында» 2011 елның 24 гыйнварындагы 19 номерлы боерыгы белән расланган Атмосфера һавасына стационар чыганаклардан зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм юкка чыгару буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентка (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Регламент тексты буенча «министр урынбасары» сүзләрен «министрның беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының атмосфера һавасына стационар чыганаклардан зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 апрелендәге 143-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының атмосфера һавасына стационар чыганаклардан зарарлы (пычраткыч) матдәләр чыгаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: 2 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты»;

2.4 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Рөхсәт бирү гаризаны теркәгәннән соң 23 эш көне эчендә, әмма 30 календарь көннән дә артык булмаган чорда гамәлгә ашырыла»;

3 бүлекнең 3.3 пунктындагы 3.3.1 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.8 пунктын өстәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән тиешле органнарга җибәрә»;

Регламент тексты буенча «министр урынбасары» сүзләрен «министрның беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының начар метеорология шартлары булган чорда атмосферага чыгарыла торган зыянлы (пычраткыч) матдәләрне киметү буенча чаралар планын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 апрелендәге 144-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының начар метеорология шартлары булган чорда атмосферага чыгарыла торган зыянлы (пычраткыч) матдәләрне киметү буенча чаралар планын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба -Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертегә:

2 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты»;

3 нче бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре»;

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.9 пунктын өстәргә:

«5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән тиешле органнарга җибәрә»;

Регламент тексты буенча «министр урынбасары» сүзләрен «министрның беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга; Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Пычраткыч матдә чыгаруның чик дәрәҗәдә мөмкин булган нормативларына һәм пычраткыч матдә ташлауның рөхсәт ителгән нормативларына ирешү өчен әйләнә-тирә мохиткә чыгарыла, ташлана торган пычраткыч матдәләрне киметү буенча чаралар планын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 20 апрелендәге 145-п номерлы боерыгы белән расланган Пычраткыч матдә чыгаруның чик дәрәҗәдә мөмкин булган нормативларына һәм пычраткыч матдә ташлауның рөхсәт ителгән нормативларына ирешү өчен әйләнә-тирә

мохиткә чыгарыла, ташлана торган пычраткыч матдәләрне киметү буенча чаралар планын килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:»2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты»;

3 бүлектә:

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре»;

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.1.8 пунктын өстәргә:

«5.1.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән тиешле органнарга җибәрә»;

Регламент тексты буенча «министр урынбасары» сүзләрен «министрның беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.

5. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү контролен гамәлгә ашыру тәртибен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 апрелендәге 146-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү контролен гамәлгә ашыру тәртибен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:»2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты»;

2.4 пунктының 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рөхсәтләрне бирү гаризаны теркәгәннән соң 23 эш көне эчендә башкарыла, ләкин 30 календарь көннән дә артык түгел»;

2.5 пунктта:

2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү контролен гамәлгә ашыру тәртибен килештерү турында гариза (1 нче кушымта)»;

18 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү контролен үтәү буенча хисап кабул итү турында гариза (3 нче кушымтасы)»;

3 бүлектә:

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре»;

3.1 пунктның 3.1.2 пунктчасында «4» санын «5» санына алмаштырырга;

3 бүлегендәге 3.3 пунктының 3.3.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми»; 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.9 пунктын өстәргә:

«5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән тиешле органнарга җибәрә»;

Регламент тексты буенча «министр урынбасары» сүзләрен «министрның беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга.

6. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 23 апрелендәге 147-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

2 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты»; 2.10 пунктында «РФ Салым кодексының 333.33 ст. 116 п.» сүзләрен «РФ Салым кодексының 333.33 ст. 1 п. 116 п.п.» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре»;

3.1 пунктның 3.1.2 пунктчасында «4» санын «5» санына алмаштырырга;

3 бүлегендәге 3.3 пунктының 3.3.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.1.9 пунктын өстәргә:

«5.1.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән тиешле органнарга җибәрә»;

Регламент тексты буенча «министр урынбасары» сүзләрен «министрның беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка кушымтаны (белешмәлекне) үз көчен югалткан дип танырга.

7. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Калдыклар барлыкка килү, аларны файдалану, зарарсызлау һәм урнаштыру турында хисапларны (статистик хисаплардан тыш) кабул итү турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2012 елның 23 апрелендәге 148-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Калдыклар барлыкка килү, аларны файдалану, зарарсызлау һәм урнаштыру турында хисапларны (статистик хисаплардан тыш) кабул итү турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты»;

3 бүлектә:

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре»;

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми»;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 5.9 пунктын өстәргә:

«5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән тиешле органнарга җибәрә»;

Регламент тексты буенча «министр урынбасары» сүзләрен «министрның беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга.

8. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (В.А.Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәү өчен җибәрергә.

9. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр вазыйфаларын башкаручы Р.И.Камалов